КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 28 гыйнвар г.Казань № б-136

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтаның 2.1 пункты нигезендә:

1. Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 28 гыйнвар, б-136 нчы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга озак вакытлы карау системасын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында төзелгән күмәк киңәшмә орган булып тора.

2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Эшче төркем түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру чараларын (алга таба – пилот проекты) тормышка ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының ведомствоара хезмәттәшлеген һәм гамәлләре килешүен тәэмин итүне;

пилот проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары вәкилләрен тыңлауны;

пилот проекты чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килгән мәсьәләләрне карап тикшерүне;

пилот проектын гамәлгә ашыру барышын системалы анализлауны һәм бәяләүне;

пилот проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча карарлар кабул итүне.

4. Эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча кирәкле материалларны федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча

территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм башка оешмалардан билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның вазыйфаи затларын чакырырга;

үз вәкилләрен федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни һәм башка оешмалар тарафыннан үткәрелә, пилот проектына кагылышлы мәсьәләләр тикшерелә торган чараларда катнашуга җибәрергә.

5. Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана. Эшче төркем аның җитәкчесе, җитәкче урынбасары һәм әгъзалары составында төзелә.

6. Эшче төркем җитәкчесе эшче төркем эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә, эшче төркем утырышларының көн тәртибен һәм үткәрү вакытын билгели, үз компетенциясе чикләрендә эшче төркем әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

7. Эшче төркем үз эшчәнлеген утырышлар үткәрү юлы белән гамәлгә ашыра.

Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

8. Эшче төркем утырышларын эшче төркем җитәкчесе, ул булмаганда яки аның кушуы буенча эшче төркем җитәкчесе урынбасары үткәрә.

9. Эшче төркем утырышлары, әгәр дә аларда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала.

10. Эшче төркем карарлары утырышта катнашучы эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, эшче төркем утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

11. Эшче төркем карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырыш үткәрелгән көннән биш эш көне эчендә утырышта рәислек итүченең имзасы куела һәм эш төркеме әгъзаларына җибәрелә.

12. Эшче төркем эшчәнлеген Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тәэмин итә.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021ел, 28 гыйнвар, б-136 нчы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру чаралары комплексын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Алишева Светлана Нурислам кызы | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесенең учреждение эшчәнлегенең гомуми мәсьәләләре буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Закиров Фердинат Равил улы | Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесе идарәчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәммәтдинов Рамил Рафиз улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече-гериатры (килешү буенча) |
| Полякова Елена Петровна | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе – дәүләт учреждениесе идарәчесе (килешү буенча). |

---